**ГЛАВА**
**Красноборского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Красный Бор авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2019 Красный Бор авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Красный Бор авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07. 2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 9 декабрендә 14 сәг 00 минутта Красный Бор авылы мәдәният йорты бинасында Красный Бор авылында Көнчыгыш ур., Маркс ур., Новая ур., Красный Бор ур., Коммунальная ур., Ком ур., Маркин ур., 1-20,21,22,24,26,27 йортлар, Юность ур., Гагарин ур., Набережная ур., Спорт, Трудовая ур., Заречная ур., Горная ур., Лесная ур., 1, 3, 5, 7 йортлары үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
2. 2019 елның 10 декабрендә 14 сәг 00 минутта Красный Бор авылы мәдәният йорты бинасында Красный Бор авылында Төзүчеләр ур., 9,11,2,6,8,10 йортлар, Горький ур., Яшьләр ур., Сельхозтехника ур., Октябрь ур., Толстой ур., Маркин ур., 37 35,36,38,39,40,41,42,43,44,45,46,47,48,49,55,61,63 йортлары, Совхоз ур., Подгорная ур., Елга ур., Кама ур. үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
3. Гражданнар җыены этапларын уздыру һәм оештыру Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә итеп расларга:

« I һәм II төркем инвалидлары, өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлар, раслаучы документлары булган очракта,

ирекле халык дружинасы әгъзалары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган, 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндә санап кителгән эшләрне башкаруга тоту белән килешәсезме?

- Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге территорияне төзекләндерү:
- Кызыл Бор авылы урамнарын кардан чистарту
- Кызыл Бор авыллары зираты территориясен төзекләндерү
- Гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау, вак таш җәю.
- Урамнарны яктырту өчен лампалар сатып алу.
- Кызыл Бор авылында балалар мәйданчыгы төзү, балалар өчен уен комплекслары сатып алу һәм урнаштыру;
- Кызыл Бор авылында тротуарлар төзү
- Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча, шулай ук Красный Бор авыл җирлегенең башка мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этаплары үткәрелергә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

А.Н. ЛАЗАРЕВ